Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

**“Янгын куркынычсызлыгы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2007 елның 5 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Янгын куркынычсызлыгы турында” 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11-12; 1994, № 1-2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 2, № 11; 1999, № 3; 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2005, № 2; 2007, №7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Янгынга каршы дәүләт хезмәте көчләре белән янгын сүндерүне оештыру (урман янгыннарыннан, ябык административ-территориаль берәмлекләрдәге янгыннардан, илнең милли иминлеге өчен критик мөһим объектларның, янгын куркынычы булган башка аеруча мөһим объектларның, Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирасының аеруча кыйммәткә ия объектларының Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган исемлегенә керүче объектлардагы янгыннардан гайре, шулай ук күп кешеле федераль дәрәҗәдәге чаралар уздырганда);”;

түбәндәге эчтәлекле яңа унөченче абзац өстәргә:

“федераль башкарма хакимият органының янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле территориаль органы

бүлекчәләренә субвенцияләр бирмичә генә вәкаләтләр алмашу тәртибендә гамәлгә ашырыла торган оператив идарә;”;

унөченче абзацны ундүртенче абзац дип санарга;

2) 18 статьяның алтынчы өлеше үз көчен югалткан дип танырга;

3) 19 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“Янгыннан саклау бүлекчәләренең көчләрен һәм акчаларын янгыннарны сүндерү өчен җәлеп итү тәртибе федераль башкарма хакимиятнең янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле органы тарафыннан раслана.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2007 елның 21 апреле

№ 15-ТРЗ